# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

1994 елнын 1 кварталында Татарстан
Республикасы бюджетыннан дәүләт
чыгымнарын финанслау турында

Татарстан Республикасы бюджетыннан дәүләт чыгымнарын әзлекле финанслауны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Югары Советы КАРАР БИРӘ:

1 статья. Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына, хезмәт өчен түләүнең минималь күләме индексының үзгәрүен исәпкә алып, 1994 елның 1 кварталында 1993 елның 1У кварталындагы финанслауның өчтән бере күләмендә ай саен дәүләт чыгымнарын финанслауны рөхсәт итәргә.

2 статья. Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына әстәлгән бәяләргә салым буенча һәм табышка салым буенча кирәк очракларда ташламалар бирүне рөхсәт итәргә.

3 статья. Татарстан Республикасының Милли банкы 1994 елның 1 кварталында Татарстан Республикасының республика һәм җирле бюджетлары керемнәре үтәлешен исәпкә алуның гамәлдәге системасын сакларга тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Ш.Шәймиев

Казан шәһәре,
1994 елның 8 феврале
N 2065-ХП